ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«25 »апрель 2022 ел № 56-р

«Өченче буын университетын» оештыру турында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы пенсионерларының хокукларын һәм тормыш мәнфәгатьләрен яклау, актив яшәү рәвешенә җәлеп итү, өлкән яшьтәге кешеләргә карата районның иҗтимагый һәм икътисадый тормышының төрле өлкәләрендә социаль активлыкны арттыру юлы белән өлкән яшьтәге гражданнарга ихтыяҗ артуны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 26 августындагы 2071-р номерлы “2019-2024 елларга Татарстан Республикасында өлкән буын гражданнарга системалы ярдәм күрсәтүнең һәм тормыш сыйфатын күтәрүнең региональ комплекслы планы (программасы) турында” күрсәтмәсе, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «2017-2020 елларга Россия Федерациясендә өлкән буын гражданнары мәнфәгатьләрендәге гамәлләр стратегиясенең беренче этабын Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру буенча чаралар планын үтәү буенча Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының чаралар исемлеген раслау турында»2017 елның 2 маендагы 1012 номерлы боерыгы, ә шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 14 августындагы 25-53/10626 номерлы «Татарстан Республикасында яшәүчеләрне пенсия алды һәм пенсия яшендәге яшьтәгеләрне 2018-2025 елларга җәлеп итү буенча чараларның республика планын җибәрү турында» хаты нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында Россия пенсионерлар берлегенең Әгерҗе җирле бүлекчәсе базасында “Өченче буын университеты” уку төркемнәрен ачарга.

2. Россия Пенсионерлар берлегенең җирле бүлекчәсе рәисе Л.И.Бодрицкаяга, Әгерҗе районында ПФР бүлегенең клиент хезмәте (хокукларда) җитәкчесе З.Ш.Бакасовага «Өченче буын университеты» кысаларында заманча белем нигезләренә укырга теләүче гражданнардан гаризалар кабул итүне оештырырга, уку планын һәм укыту программаларын эшләргә тәкъдим итәргә.

3. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы В.Г. Сафиуллинага, «Әгерҗе үзәкләштерелгән китапханә системасы» МБУК директоры Э.Р. Капиловага үзләренең карамагындагы учреждениеләр базасында пенсионерларны укытуны оештыруда ярдәм күрсәтергә.

4. Әлеге күрсәтмәне Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының Эшләр идарәчесе Э.Р. Рыковага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**